**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«11» апрель 2016 ел Түбән Суыксу авылы № 8

«2016-2018 елларга Түбән Суыксу авыл җирлеге территориясендә эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүгә ярдәм итү программасы» кысаларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү өчен муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатында, "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законны, "Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2010 елның 21 январендагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «2016 – 2018 елларга Түбән Суыксу авыл җирлеге территориясендә эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүгә ярдәм итү” программасын үтәү йөзеннән,

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбән Суыксу авыл җирлеге территориясендә эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә ярдәм күрсәтү өчен мөлкәт исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны рәсми сайтТа һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Н.М. Сәйфетдинов